РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«31» октябрь 2019 с. Тюлячи № 614

«Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының гражданлык яклау идарәсе» муниципаль казна учреждениесен Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы идарәнең даими эшләүче органы һәм Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә махсус вәкаләткә ия дип билгеләү турында

«Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнарны гамәлгә ашыру максатларында, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының гражданлык яклау идарәсе» муниципаль казна учреждениесен Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы идарәнең даими эшләүче органы һәм Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә махсус вәкаләткә ия дип билгеләргә.

2. 2019 елның 31 декабренә кадәр «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының гражданлык яклау идарәсе» муниципаль казна учреждениесе директорына (И.Ә. Нәҗмиев), билгеләнгән тәртиптә, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау чараларын планлаштыру һәм уздыруны оештыру документларын эшләргә һәм аларны килештерергә.

3. «Татарстан Республикасы буенча федераль янгынга каршы хезмәтнең 7 отряды» (Шәрипов М.М.) федераль дәүләт казна учреждениесенең 134 янгын сүндерү бүлеге начальнигына халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә документларны эшләүдә

«Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының гражданлык яклау идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә карата методик һәм гамәли ярдәм күрсәтүне тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Х. Хәмидуллинга йөкләргә.

Җитәкче Н.Н. Хаҗипов